# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Җәмәгать эшләре турында

Әлеге Закон җәмәгать эшләрен оештыру өчен кулланыла торган хезмәт эшчәнлегенең максатларын, юнәлешләрен, җәмәгать эшләрен оештырганда җирле администрацияләрнең, җирле үзидарә органнарының, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органнары вәкаләтләрен, җәмәгать эшләрен оештыру һәм аларны финанслау тәртибен билгели.

1 статья. **Җәмәгать эшләре төшенчәсе**

Социаль файдалы юнәлеше булган һәм эш эзләүче гражданнарга өстәмә социаль ярдәм итү сыйфатында оештырылучы бөтен кеше башкара алырлык хезмәт эшчәнлеге җәмәгать эшләре дип санала.

2 статья. **Җәмәгать эшләрен оештыру максатлары**

Җәмәгать эшләре түбәндәге максатларда оештырыла:

икътисадый һәм социаль үсешнең максатчыл федераль, республика һәм җирле программаларын үтәү;

Татарстан Республикасы шәһәрләрендәге һәм районнарындагы хезмәт базарында социаль киеренкелекне киметү;

халыкны эш белән вакытлыча тәэмин итү;

халык хуҗалыгы тармакларының вакытлы һәм сезонлы характердагы эшләрне үтәүдәге ихтыяҗларын гамәлгә ашыру;

озак эшләми торган яисә эш тәҗрибәсе булмаган затларның хезмәткә омтылышын саклап калу;

гражданнарга вакытлы хезмәт хакы рәвешендә матди булышлык итү.

3 статья. **Җәмәгать эшләре оештыру өчен кулланыла торган хезмәт эшчәнлеге юнәлешләре**

Җәмәгать эшләре ярдәмче, булышлык итү һәм башка квалификациясез эшләрне үтәү өчен түбәндәге юнәлешләрдә оештырылырга мөмкин:

автомобиль юлларын салу һәм аларны карап тору;

сүүткәргеч, газ, канализация һәм башка коммуникацияләрне салу;

авыл хуҗалыгы мелиоратив (ирригацион) эшләрен башкару;

авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, эшкәртү һәм саклау;

урман хуҗалыгында эшләр башкару;

торак фонды һәм социаль-мәдәни объектларны төзү һәм реконструкцияләү;

тарихи-архитектур ядкярләрне, комплексларны һәм тыюлык зоналарын торгызу;

пассажир транспортына хезмәт күрсәтү;

элемтә оешмаларында эшләү;

торак-коммуналь хуҗалыгын эксплуатацияләү һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү;

территорияләрне яшелләндерү һәм төзекләндерү, урман-парк хуҗалыгын, ял итү һәм туризм зоналарын үстерү;

өлкәннәрне, инвалидларны һәм авыруларны карау;

каникуллар чорында балаларны савыктыру һәм ял иттерү объектларына, шифаханә-курорт зоналарына хезмәт күрсәтү;

икенчел чималны һәм калдыкларны җыю һәм эшкәртү;

иҗтимагый-мәдәни гамәлләрне (халык санын алу, спорт ярышлары, фестивальләр һ.б.) уздырганда катнашу;

хезмәт эшчәнлегенен һәркем башкарырлык бүтән төрләре.

4 статья. **Гражданнарның җәмәгать эшләрендә катнашулары**

Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенен дәүләт органнарында теркәлгән гражданнар шушы органнарнын юлламалары буенча җәмәгать эшләрендә катнашырга хокуклы.

Гражданнарнын җәмәгать эшләрендә катнашуы алар ризалыгы белән генә рөхсәт ителә.

Җәмәгать эшләренә катнашуда өстенлекле хокукка түбәндәгеләр ия була:

законнар нигезендә социаль яклауга аеручa мохтаж һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнар;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органнарында алты айдан да артыграк исәптә торган эшсез гражданнар;

эшсезлек буенча пособие алмаучы эшсез гражданнар.

5 статья. **Дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының һәм җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарының вәкаләтләре**

Халык депутатларының җирле Советы, җирле үзидарәнең вәкиллекле органы җәмәгать эшләрен финанслауга тиешле бюджетларда акчаларны алдан күздә тотарга хокуклы.

Җирле администрация, җирле үзидарә органы җәмәгать эшләрен оештыру һәм аларны оештыруны тикшереп тору буенча халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органнары белән хезмәттәшлек итәләр.

Җирле администрация, җирле үзидарә органы җәмәгать эшләрен оештыру, аларны уздыру тәртибе, хезмәт өчен түләү шартлары, шулай ук җәмәгать эшләрен башкарганда эш бирүчеләр бирә торган өстенлекле ташламалар турында гражданнарга мәгълүмат җиткерү эшен башкаралар.

Халык депутатларының җирле Советы, җирле үзидарәнең вәкиллекле органы, үз акчаларын җәлеп итеп җәмәгать эшләрен оештыручы эш бирүчеләргә җирле салымнар һәм җыемнар буенча өстәмә ташламалы өстенлекләр бирергә хокуклы.

6 статья. **Эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органнары вәкаләтләре**

Эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органнары җәмәгать эшләрен оештыру турында ел саен җирле администрациягә, җирле үзидарә органына тәкъдимнәр кертә.

Эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органнары түбәндәге мәгълүматларны бирәләр:

эш эзләүче гражданнарга җәмәгать эшләрен оештыру, аларны башкару тәртибе, хезмәт өчен түләү шартлары турында, шулай ук җәмәгать эшләрен башкарганда эш бирүчеләр тәкъдим итә торган өстенлекле ташламалар турында;

җәмәгать эшләрен оештырганда эш бирүчеләргә җирле салымнар һәм җыемнар буенча законнар нигезендә өстенлекле ташламалар бирү турында.

Эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органнары гражданнарны җәмәгать эшләрен башкару өчен оешмаларга җибәрәләр һәм аларның исәбен алып баралар.

Эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органнары җәмәгать эшләрен оештырганда эш бирүчеләрнең хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарны үтәүләрен тикшереп торалар.

129

7 статья. **Җәмәгать эшләрен оештыруда һәм башкаруда катнашучы якларның хокукый мөнәсәбәтләре**

Җәмәгать эшләрен оештыруда һәм башкаруда катнашучы якларны җирле администрация, җирле үзидарә органы, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органы, эш бирүче, граждан тәшкил итәләр.

Җирле администрация, җирле үзидарә органы, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органы һәм эш бирүче арасындагы мөнәсәбәтләр җәмәгать эшләрен оештыру һәм башкару буенча уртак эшчәнлек турындагы шартнамәләр белән җайга салына.

Җәмәгать эшләрендә катнашырга теләүче гражданнар белән эш бирүче гражданның җәмәгать эшләрендә катнашуы турында вакытлы хезмәт шартнамәсе төзи.

Гражданның җәмәгать эшләрендә катнашуы турындагы шартнамә граждан даими йә вакытлыча эшкә урнашкан очракта яисә башка сәбәпләр буенча законнар нигезендә вакытыннан алда өзелергә мөмкин.

Эш бирүчеләр җәмәгать эшләрендә катнашучы гражданнарга үз акчалары исәбенә өстәмә өстенлекле ташламалар бирергә хокуклы.

8 статья. **Эш урыннарын оештыру**

Эш бирүчеләр җәмәгать эшләрен оештыру буенча уртак эшчәнлек турындагы шартнамәләр нигезендә җәмәгать эшләрен башкару өчен вакытлы өстәмә эш урыннары оештыралар.

Җәмәгать эшләрен оештырганда эш бирүчеләрдә булган даими эш урыннарын һәм вакантлы урыннарны куллану рөхсәт ителми.

9 статья. **Җәмәгать эшләрендә хезмәт өчен түләү**

Җәмәгать эшләре белән шөгыльләнүче гражданнарга хезмәт өчен түләү законнар нигезендә башкарыла.

10 статья. **Җәмәгать эшләрен финанслау чыганаклары һәм тәртибе**

Җәмәгать эшләрен финанслау эш бирүчеләрнең акчалары, җирле бюджетлар акчалары, Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары һәм законнарда тыелмаган башка чыганаклар исәбенә башкарыла.

Җәмәгать эшләрен финанслауга Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларын бүлеп бирү һәм аларны тоту тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 сентябре
№ 1076